КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 июль г.Казань № 598

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 30 июль, 531 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 30 июль, 531 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 9 июль, 478 нче; 2015 ел, 4 июнь, 406 нчы; 2015 ел, 26 сентябрь, 711 нче; 2016 ел, 29 апрель, 262 нче; 2017 ел, 10 май, 270 нче; 2018 ел, 26 апрель, 292 нче; 2019 ел, 4 сентябрь, 750 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә «2014 – 2021» саннарын «2014 – 2024» саннарына алыштырырга;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман хуҗалыгын үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 318 номерлы карары белән расланган «Урман хуҗалыгын үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

карарның 1 нче пунктында «2014 – 2021» саннарын «2014 – 2024» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин